**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 9 август № 546

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга балалар ризыгының махсус сөт продуктлары белән түләүсез тәэмин итү өчен норматив чыгымнарны раслау турында» 2015 ел, 18 ноябрь, 869 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга балалар ризыгының махсус сөт продуктлары белән түләүсез тәэмин итү өчен норматив чыгымнарны раслау турында» 2015 ел, 18 ноябрь, 869 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территорияләрендә урнашкан медицина оешмалары каршындагы сөт өләшү пунктлары һәм яхшы сыйфатлы туклану пунктлары аша өч яшькә кадәрге балаларны балалар ризыгының махсус сөт продуктлары белән түләүсез тәэмин итүгә норматив чыгымнарга түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «ВИЧ-инфекцияле аналардан туган балалар һәм ВИЧ-инфекцияле балалар | 36,88 | - | -»; |

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны балалар ризыгының махсус сөт продуктлары белән түләүсез тәэмин итүгә хезмәтләр күрсәтү күләмнәре нормативларында:

«909 144» саннарын «883 890» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «ВИЧ-инфекцияле аналардан туган балалар һәм ВИЧ-инфекцияле балалар | 0 айдан 6 айга кадәр | 25 254 | - | - | -». |

2. Бу карарның гамәле 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков